**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН БӘРӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**СОВЕТ НИЖНЕБЕРЕСКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422743 Республика Татарстан Атнинский район село Нижняя Береске Тел. 3-34-03

**КАРАР**

«04» апрель 2025 ел

№117

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 8 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) адресы буенча, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт (администрация бинасы);

Олы Бәрәзә авылы, Большая урамы, 37а йорт (КФҮ бинасы) халыкка җиткерергә.

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнебересканского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1610000476 ОГРН 1046061554405

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
117 нче номерлы карарына 1 нче кушымта


Түбән Бәрәскә авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы,** Ленин урамы, № 12 - № 62 йортлар, Совет урамы, № 52 - № 64 йортлар | 102 |
| 2 | 2 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы,** Совет урамы, № 1 - № 50 йортлар | 99 |
| 3 | 3 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы**, Культурная урамы, Казаклар урамы, Тукай урамы, Центральная урамы | 111 |
| 4 | 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы,** Ленин урамы, № 1 - № 10 йортлар, Новая урамы | 97 |
| 5 | 5 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы,** Чишмәле урамы, Зеленая урамы, № 1 - № 4 йортлар | 99 |
| 6 | 6 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Бәрәскә авылы,** Зеленая урамы, № 5 - № 18 йортлар, Мира урамы, Татарстан урамы | 95 |
| 7 | 7 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Олы Бәрәзә авылы,** Большая урамы, Центральная урамы, № 28, № 30, № 32, № 35, № 37 йортлар, Строителей урамы | 110 |
| 8 | 8 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Олы Бәрәзә авылы,** Центральная урамы, № 1 - № 27, № 29, № 31, № 33 йортлар, Таллык урамы, Чишмәле урамы, С.Хәким урамы, Зеленая урамы | 113 |
| 9 | 9 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы | **Олы Бәрәзә авылы,** Ленин урамы, Тукай урамы, Чүлмәнчек урамы, Яшьлек урамы; **Олы Өшкәтә авылы** | 109 |
| 10 | 10 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы | **Олы Бәрәзә авылы,** М.Җәлил урамы, Школьная урамы | 113 |


Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
117 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**

Түбән Бәрәскә авылы




Олы Бәрәзә авылы




Олы Өшкәтә авылы

